**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Дуртмунчинского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

Ул. Молодежная, д.148, с Дурт-Мунча, Заинский район, 423515

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Дүрт-Мунча авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

Яшьләр урамы, 148 нче йорт, Дүрт-Мунча авылы, Зәй районы, 423515

Телефон, факс 6-03-10. Электронный адрес: Durt.zai@tatar.ru, сайт: www.Durtmuncha.ucoz.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№** 9 **от** 31.07.2019г

**«Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында»**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2019 нчы елның 10 нчы июлендәге 67/516 номерлы «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» карары, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә

**карар бирәм:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге сайлау участоклары территориясендә махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен урыннар исемлеген расларга (Кушымта).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карарны Зәй муниципаль районы сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә Дүрт-Мунча авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет житәкчесе** **Р.Т.Ситдиков**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Дурт-Мунча авыл җирлеге
Башкарма комитет карарына
Кушымта
31.09.2019 № 9

**Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә урыннар исемлеге**

| № п/п | Сайлау участогы № | Объектның исеме һәм урнашу адресы |
|---|---|---|
| 1. | 1473 | Мәгълүмат стенды<br>Дүрт-Мунча авылы, Үзәк ур., 95”а” йорт |
| 2. | 1473 | Мәгълүмат стенды<br>Кабан-Бастрык авылы, Үзәк ур.,64 йорт |
| 3. | 1474 | Мәгълүмат стенды<br>Зичәбаш авылы, Үзәк ур.,36 “а” йорт |